2012

ГАЛИЕВА Р.М., САБИРОВА Л.Р.

ЯЗМА ФӘННИ ЭШЛӘР: ЖУРНАЛИСТИКА БҮЛЕГЕНДӘ УКУЧЫ СТУДЕНТЛАР ӨЧЕН МЕТОДИК КУЛЛАНМА

Укыту-методик кулланма

Казан (Идел буе) федераль университеты

УДК 070

Казан (Идел буе) федераль университеты журналистика һәм социология факультетының укыту-методик комиссиясе (беркетмә № 3, 19.03.2011)

һәм татар журналистикасы кафедрасы (беркетмә №6, 6.03.2011) утырышларының карары нигезендә басыла

Фәнни редактор:
филология фәннәре докторы, профессор **В.З. Гарифуллин**

Рецензентлар:
филология фәннәре кандидаты, доцент **Р.Л. Зәйни**
филология фәннәре кандидаты, **А.Ф. Галиәхмәтова**

Галиева Р.М., Сабирова Л.Р.

Язма фәнни эшләр: журналистика бүлегендә укучы студентлар өчен методик кулланма. Казан: Казан ун-ты нђшр, 2012. 51 б.

Укыту-методик кулланмада журналистика бүлегендә язма фәнни эшләр язуның үзенчәлекләре, баскычлары, төрләре, курс һәм диплом эшенђ куела торган таләпләр, кагыйдәләр бирелә, темалар тәкъдим ителә.

Укыту-методик кулланма югары уку йортларының “Журналистика” белгечлеге буенча белем алучы студентларга юллана.

КЕРЕШ

Фәнни язма эш (гыйльми мәкалә, фәнни доклад, контроль эш, реферат, курс һәм чыгарылыш квалификация (диплом) эше керә) – студентның эрудициясен, шәхси сәләтен күрсәтә торган катлаулы фәнни иҗат нәтиҗәсе. Журналистика бүлеге студентлары ике төрдәге фәнни хезмәт башкара ала:

1.Нәзари (теоретик);

2. Нәзари-иҗади.

Нәзари фәнни эштә студент журналистика теориясе, тарихы, матбугат типлары, жанрлар, мәгълүмат чараларының төрләре, радио, телевидение һәм электрон басмаларның актуаль проблемаларын соңгы фәнни-тикшеренү нәтиҗәләренә таянып анализлый. Шулай ук бүгенге социаль-икътисадый шартларда дөньякүләм һәм халыкара журналистиканың үсеш тенденцияләре тикшерелә.

Нәзари-иҗади эшнең үзенчәлеге шунда: тикшеренү объекты итеп авторның үз иҗаты алына. Әйтик, нинди дә булса темага бәйле язмалар циклы, бер үк жанрдагы әсәрләр. Иҗади фәнни эш автордан массакүләм мәгълүмат чараларында (алга таба – ММЧ) бәян ителгән хезмәтләре булу белән беррәттән төпле тематик белем, фәнни эзләнүләр таләп итә. Әлбәттә, студент үзен төп иҗатчы буларак тәкъдим итүе мактауга лаек, әмма бу эш җиңел дип уйлаучылар ялгыша. Ул үз иҗатын мәгълүмат чараларының гомуми эшчәнлеге яссылыгында анализларга һәм үрнәк булырдай, тәҗрибәле журналистлар иҗаты белән чагыштырырга тиеш.

Курс һәм диплом эше мөстәкыйль языла. Ул студенттан киеренке хезмәт, тикшерү осталыгы һәм хатасыз башкарылуны, әдәбият һәм чыганаклар исемлеген соңгы елларда кабул ителгән дәүләт стандарты кагыйдәләренә тулысынча туры китерелүне таләп итә. Шул җәһәттән, әлеге укыту-методик кулланма фәнни эшне ничек сайларга, ничек төзергә, чыганаклар, астөшермәләр белән эш итәргә ярдәм итәчәк.

Журналистика бүлегендә студентлар **контроль эш** һәм **реферат** язалар. Аларның үзенчәлеге шунда: гадәттә бу төр эшләр уку семестры барышында башкарыла. Зачет яисә имтихан алдыннан бәяләнә.

Контроль эш укытучы тарафыннан әзерләнә, ул төрле формада булырга мөмкин. Мәсәлән, әдәби-публицистик жанрлар (сатира) курсын үзләштерүче студентлар мәзәк, сатирик характеристика һәм фельетон язу буенча контроль эшләр башкаралар. Соңгы вакытта тест рәвешендә тәкъдим ителгән контроль эш төрләре гамәлгә керә башлады.

Реферат – татар журналистикасы кафедрасында иҗадыйлыкны таләп итә торган фәнни эш төре. Ул язмача башкарыла. Фәнни хезмәткә куелган

таләпләр, бурыч-максатлар, теманың актуальлеге ачыклана. Мәсәлән, “Журналист осталыгы” курсыннан реферат язарга тәкъдим ителде ди. Студент “Шәһри Казан”ның баш мөхәррире, журналист Мансур Мортазин иҗатын өйрәнергә теләк белдерә. Рефератның герое турында язганчы, ул аның язмаларын өйрәнергә, бер үк вакытта “Журналист осталыгы”, “Журналист эшчәнлеге нигезләре” кебек дәреслекләр белән танышырга тиеш була. Аннан соң ул тикшерү объекты белән очрашып сөйләшә ала. Мондый төр нәзари-иҗади рефератлардан тыш, журналистика тарихы һәм вакытлы матбугаттагы жанрларның төрләре һәм төзелеш үзенчәлекләре буенча нәзари (теоретик) рефератлар да язылырга мөмкин.

ФӘННИ ЭШНЕҢ БАСКЫЧЛАРЫ

Язма фәнни эш *тема сайлаудан* башлана. Аны кафедра, фәнни җитәкче яисә студент үзе тәкъдим итәргә мөмкин. Курс эшләре буенча темалар уку елы башында кафедра утырышында раслана. Чыгарылыш квалификация эше темалары исә алданрак, ягъни узып баручы уку елының азагында раслана. Моның өчен булачак дипломчы, сайларга теләгән теманың исемен һәм фәнни җитәкчесен күрсәтеп, кафедра мөдире исеменә гариза яза.

Тема, беренче чиратта, студентның үзендә кызыксыну уятырга тиеш. Аның ялгыш сайлануы фәнни эшнең дәвамлылыгын һәм нәтиҗәлеген киметә. Шуңа күрә беренче курстан ук диплом эше дәрәҗәсенә җиткерерлек курс эше темасын сайларга кирәк.

Икенче баскыч – китапханәдә, архивта эшләү, ягъни *материал туплау*. Тема расланганнан соң, эшнең хронологик кысалары билгеләнә, тикшеренү объекты тәгаенләнә. Фәнни җитәкче сайланган темага кагылышлы әдәбият исемлеген тәкъдим итә. Китапханәдә эшләү барышында студент тематик каталоглардан да файдалана ала, ягъни үзе өйрәнә торган темага кагылышлы барлык фәнни әдәбиятны карап чыга, шулар арасыннан үзенә аеруча кирәклесен сайлый. Иң мөһиме, авторның фамилиясен һәм инициалларын, баш исемен, басылып чыккан елын, шәһәрен, нәшриятен, китапның бит санын дөрес итеп күрсәтергә кирәк. ГОСТ (дәүләт стандартлары) таләпләренә нигезләнеп, фәнни эшнең чыганаклары һәм әдәбият исемлеге тутырыла. Архив документларының саклану урынын, нинди сан астында, кайсы бүлектә урнаштырылуын ачыклау мөһим.

Тикшерү объекты итеп газета-журналларда басылган язмалар, радио һәм телевидение тапшырулары сайлана. Әлбәттә, аерым бер курс эшендә күп еллар дәвамында басылган яисә эфирдан яңгыраган материалларны колачлау мөмкин түгел. Димәк, тикшеренү өчен сайланган текстлар вакыты чикләнгән хронологик тәртиптә алына. Материалны темада күтәрелгән проблема яссылыгында өйрәнергә кирәк, фактларның тирәнтен анализы таләп ителә. Темага ярашлы берничә китаптан тыш, шулай ук әлеге мәсьәләгә кагылышлы фәнни мәкаләләргә дә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Автор фикере сылтама (цитата) рәвешендә куштырнаклар эчендә бирелә. Студентның максаты – проблемаларны күрсәтү генә түгел, үз карашын билгеләү, журналист эшчәнлегенә бәя бирү, проблеманы ачуда аның үзенчәлеген табу, аңлау, анализлау. Кимчелекле яклары булса, сәбәпләрен ачыклау, дәлилләү, төзәтү юлларын күрсәтү.

Өченче баскыч – *план төзү*. Аны, һичшиксез, фәнни җитәкче белән бергәләп камилләштерергә кирәк. Язма фәнни эш, гадәттә, өч зур кисәктән тора: кереш, аерым бүлекләр, йомгак.

Дүртенче баскыч – *фәнни эшне башкару*. Бу этапта студент үз алдына куелган максат һәм бурычлар белән бәйле рәвештә өйрәнелә торган объектны анализлый, классификация үткәрә, нәтиҗәләр ясый.

Бишенче баскыч – *эшне яклау*. Фәнни эшнең караламасын студент башта җитәкчесеннән тикшертә, төзәтмәләрне исәпкә ала. Шуннан соң титул битенә үзе кул куя, җитәкченең имзасын (диплом эшенә – кафедра мөдиренең дә имзасын) ала һәм рецензентка тапшыра. Курс эшенә рецензияне авторның төркемдәше, курсташы яза ала, ә диплом эшенә кафедра тарафыннан билгеләнгән оппонент бәя бирә[1].

ФӘННИ ЭШНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

Фәнни эшнең төзелеше кереш, бүлекләр, йомгак, кулланылган фәнни әдәбият, чыганаклар һәм кушымтадан тора. Тема сайлаганнан соң, эчтәлек планы әзерләнә.

Кереш өлешендә теманың ни өчен сайлануы, аның актуальлеге, фән өчен кирәклеге нигезләнә, хезмәтнең максат-бурычлары билгеләнә, тикшеренүнең методологиясе, анализ методлары ачыклана, фәнни эшнең гамәли әһәмияте дәлилләп бирелә, файдаланылган нәзари әдәбиятка күзәтү ясала, чыганаклар даирәсе тәгаенләнә, эшнең төзелешенә кыскача күзәтү ясала[2].

Көндезге бүлекнең 5 курс (1362 нче төркем) студенты А.Р.Хәбибуллинаның чыгарылыш квалификация эшенең кереш өлешен үрнәк итеп китерәбез:

КЕРЕШ

Актуальлек. “Татмедиа” агентлыгы мәгълүматлары буенча, басма матбугаттагы барлык язмаларның 30-35 процентын мәдәни тормыш турындагы язмалар алып тора[3]. Укучы тарафыннан сорау булгач, редакторлар да мәдәният темасына урынны кызганмый. Теге яисә бу формада мәдәният-сәнгать өлкәсендә булган яңалыкларны, проблемалы язмаларны башлап

---

[1] Журналистика бүлегендә язма фәнни эшләр. Дәүләт имтиханы: методик кулланма / төзүче В.З. Гарифуллин. Казан: КДУ, 2007. Б.4.

[2] Шунда ук.

[3] Мәгълүмати хат. “Татмедиа” агентлыгы. 2010. 23 март.

язучы журналистлар да, танылган каләм әһелләре дә читт итми. Мәдәният темасына иҗат ителгән язмалар шуңа күрә бик төрле. Күләм ягыннан да (кыска хроника-хәбәрләрдән башлап, зур аналитик мәкаләләр, күзәтүләргә кадәр), сыйфат ягыннан да төрлесен табып була. Арада “җиңел” интервьюлар да, теманы аңлап, бөтен шартына туры китереп язылган рецензияләр дә, проблеманы өйрәнеп, анализлап, чыгу юлларын күрсәтеп язган проблемалы мәкаләләр дә бар. Шул ук вакытта татар мәдәни журналистикасы өлкәсендә проблемалар да юк түгел. Беренчедән, тәҗрибәле, белемле кадрлар аз. Икенчедән, эстрадага игътибар күбрәк. Нәтиҗәдә, бер гасырдан күбрәк тарихы булган татар мәдәни журналистикасы бүген шактый катлаулы чор кичерә.

Әлеге гаять кызыклы теманы алуыбыз юкка түгел, чөнки театр (сүз милли театр турында гына түгел, ә гомумән театр сәнгате турында бара) бүген зур үзгәрешләр кичерә. Берәүләр бу үзгәрешләрне кабат яңарыш, үсеш, дип бәяли. Аларның дәлилләре дә бар – замана үзгәрә, таләпләр арта, шул ук вакытта техник казанышлардан файдалану мөмкинлеге дә киңәя, шуңа да театр бүген яңа, заманча формалар эзли, үсә. Шул ук вакытта, тамашачының альтернатив вариантлары күбрәк. Шуңа да театр замана артыннан чаба, тамырлары белән элемтәләрне югалта. Нәтиҗәдә, тамашачының да игътибары кими, дигән фикердә булучылар да бар. Бу шартларда мәдәни журналистикада профессиональ кадрлар булу мөһим. Сәнгать темасына язучы журналистлар күп булса да, сыйфатлы театр рецензиясе язардайлары бармак белән генә санарлык. Аларның да күбесе – журналистлар түгел, ә театр белгечләре, тәнкыйтьчеләр. Шуңа да XX гасыр башындагы тәҗрибәне өйрәнү, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Г.Кәрәм кебек каләм осталарының эш алымнарына мөрәҗәгать итү, әлеге белемнәрне системага салу бүген бик **актуаль.** Аннан, театр рецензиясен гадәттә жанр төре буларак аерып әйтмиләр. Рецензия дигәндә әдәби әсәргә язылган рецензия күз алдында тотыла. Бу хатаны төзәтергә, театр рецензиясенең дә жанр төре буларак яшәргә хокуклы икәнен расларга тырыштык.

Проблеманың өйрәнелү дәрәҗәсе. XX гасыр башындагы газета-журналлар бүгенгә шактый өйрәнелгән. Бу темага фәнни эшләр еш эшләнә. Театр тарихын өйрәнүче галимнәр дә театр рецензияләренә еш мөрәҗәгать итәләр. Мисал өчен, Р.Солтанова, А.Габәши, Д.Гыйммранова, И.Илялова кебек театр белгечләре театр темасына XX гасыр башында язылган язмаларны өйрәнгәннәр. Әмма бу эшләрдә театр рецензиясе журналистик жанр төре буларак тикшерелмәде, бәяләнмәде.

Филологлар тарафыннан да театр рецензиясенә игътибар юк, дип әйтеп булмый. Театрга багышланган эшләр соңгы елда Казан (Идел буе) федераль

университетының журналистика һәм социология факультетында да эшләнде. 2010 елда бу темага бер фәнни эш башкарылган иде (җит. Сөнгатов Г.М.), быел исә Алсу Сибгатуллина "Сәхнә" журналындагы театр рецензияләрен сөйләм объекты буларак өйрәнә (җит. Низамов И.М.). Әмма алар театр турында язылган язмаларны жанр төре буларак карамыйлар. Безнең диплом **эшенең фәнни яңалыгы** нәкъ менә шунда чагыла.

Тикшеренү **объекты** – XX гасыр башында иҗат ителгән театр рецензияләре; тикшеренү **предметы** – Г.Камал, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Кәрәм иҗатындагы театр рецензиянең үзенчәлекләре.

Фәнни эшебезнең **максаты**: XX йөз башында танылган авторлар Г.Кәрәм, Г.Тукай, Г.Камал, Ф.Әмирхан тарафыннан иҗат ителгән театр рецензияләренең жанр төре буларак формалашу һәм үсеш закончалыкларын билгеләргә.

Максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** куелды:

1. XX гасыр башы танылган журналистларының театр рецензияләрен системалаштырып өйрәнергә;
2. Театр рецензиясенең жанр төре буларак этапларын билгеләргә, жанр төре буларак, театр рецензиясенең формалашу, үсеш закончалыкларын ачыкларга;
3. Театр рецензиясенең бүгенге журналистикага йогынтысы һәм урынын билгеләргә.

Дипломның **фәнни-методологик нигезен** театр рецензиясен өйрәнүгә багышланган китаплар тәшкил итте. Алар арасында А.Салихова (Габәши)нең "Фигура Г.Карама в татарской дореволюционной театральной критике" хезмәтләрен методологик нигез буларак алдык. Журналистикага кагылышлы китаплар арасыннан методологик нигез буларак В.Гарифуллинның "Вакытлы матбугатта жанрлар" һәм А.Тертычныйның "Аналитическая журналистика: познавательно-психологический подход" китапларын сайладык.

Хезмәтне язган вакытта без чагыштырма анализ, синтез алымы кебек фәнни **метод**лардан файдаландык.

Диплом эшен язганда төп **чыганак** буларак "Казан мөхбире", "Йолдыз", "Кояш", "Вакыт" газеталарының, "Аң" журналының 1906-1916 елларда чыккан саннары кулланылды.

Фәнни эшнең **гамәли әһәмияте:** тел-сурәтләү чараларын анализлаган язмалар башлап язучы журналистлар өчен үрнәк булып тора ала.

Диплом эчтәлек, кереш, 3 бүлек, йомгак, әдәбият, чыганаклар һәм кушымтадан тора.

Фәнни язма эш үзе аерым бүлекләр, бүлекчә һәм параграфлардан торырга мөмкин. Бүлек һәм бүлекчә исемнәре фәнни хезмәтнең исеме белән тәңгәл килергә тиеш түгел. Һәр бүлек азагында кыскача нәтиҗә ясап барыла.

Йомгак өлешендә фәнни тикшерүгә нәтиҗә ясала, тикшергән проблемага бәйле рәвештә студентның үз тәкъдимнәре дә урын алырга мөмкин.

ФӘННИ ЭШНЕҢ ФОРМАСЫ

Фәнни эш компьютерда Times New Roman гарнитурындагы шрифт белән 14 кегль үлчәмендә, 1,5 интервал белән җыела, А4 форматындагы кәгазьнең бер ягына бастырыла. Битнең сул ягында 30 мм, уң ягында 10 мм, өстә 15 мм, аста 20 мм буш урын калдырыла. Курс эшенең күләме 25-35 бит, чыгарылыш квалификация эшенең 65-75 бит.

Бит саны титул бите һәм “Эчтәлек”тән соң гадәттә 3 нче биттән башлана. Бүлек яисә параграф исемнәрен төп текстан өстән, астан ике юл һәм калын шрифт белән аерырга кирәк. Һәр бүлекне яңа биттән башларга кирәк. Бүлек, бүлекчә, параграф һ.б. исеменнән соң нокта куелмый[4].

Беренче бит – фәнни язма эшнең титул бите һәм анда югары уку йортының исеме, кафедра исеме, тема, эшне язучының исем-фамилиясе, фәнни җитәкченең гыйльми дәрәҗәсе, вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары, шәһәр исеме, язылган ел күрсәтелә **(кара: 1 нче кушымта).**

Икенче биттә – эчтәлек. Ул аерым бүлекләрнең, параграфларның билгеле бер тәртиптә килүен, аларның кайсы битләрдә урнашуын күрсәтә **(кара: 2нче кушымта).**

Әдәбият фәнни хезмәтнең йомгак өлешендә бирелә һәм ул түбәндәге таләпләргә буйсынырга тиеш: башта сайлаган теманы анализлау өчен кулланылган әдәбият исемлеге языла, аннары газета-журналлар, ә иң соңыннан телерадиотапшырулар күрсәтелә. Бу исемлектән соң фәнни эштә алынган мисаллар яисә күзәтелгән чыганаклар исемлеге бирелә.

ИСКӘРМӘЛӘР ҺӘМ БИБЛИОГРАФИЯ АППАРАТЫ

Исемлекләр ике төрле тәртиптә төзелә:

1) алфавит тәртибендә;

2) хронологик тәртиптә.

Кулланылган әдәбият исемлеген дөрес итеп төзү өчен, китапханәдә эшләгәндә, китап турында мөмкин кадәр тулырак мәгълүмат күчереп алу кирәк. Мәсәлән, һәр китапның форзац өлешендә китапны бастыручы,

---

[4] Журналистика бүлегендә язма фәнни эшләр. Күрсәтелгән хезмәт. Б.5.

ничәнче елда нәшер ителгәне, бите хакында мәгълүмат була. Фәнни эшне башкаручы үзе өчен кечкенә генә каталог та әзерли ала. Чөнки фән өлкәсендә эшләүчеләр кулланылган әдәбиятны шул рәвешле саклый.

Китапның чыгарылыш мәгълүматларыннан тыш, кулланырга теләгән цитатаның кайсы битләрдә булуын да язып кую кирәк. Бу эшләрне фәнни эшкә әзерлек барышында махсус дәфтәргә теркәп бару да яхшы булыр иде. Ә инде фәнни эшне яза башлаганда теге яки бу авторның әйткән фикерләрен исбатларга яки кире кагарга мөмкин, шул чакта сезгә махсус дәфтәрегез ярдәмгә киләчәк тә инде.

Әдәбият

(ГОСТ Р 7.0.5. – 2008)

Әдәбият исемлегендә **авторы бер кеше булганда** китап турындагы мәгълүматларны болай итеп күрсәтергә кирәк:

Гарифуллин В.З. Каләм көче (Татар журналистларының текст төзү осталыгы). Казан: Казан ун-ты нәшр., 2010. 160 б.

Тертычный А.А. Аналитическая журналистика: учеб. пособие для студентов вузов. М.: Аспект Пресс, 2010. 352 с.

Ике автор китабын кулланганда:

Лазутина Г.В., Распопова С.С. Жанры журналистского творчества: учеб. пособие для вузов. М.: Аспект Пресс, 2011. 320 с.

Авторлар өчәү булган очракта:

Орлов А.Б., Латыпов Л.Д., Творогов И.И. Психологические основы воспитания. М.: Изд-во Моск. ун-та, 2000. 80 с.

Дүрт һәм аннан да күбрәк автор катнашындагы китап хакында мәгълүмат болай языла:

История России / Быков В.Н. [и др.]. СПб.: Деан, 2002. 30 с.

Җыентыклар

Татар журналистикасы XXI гасырда. Үсеш юллары: фәнни-гамәли конференция материаллары, 11 февр., 2011 ел. Казан: Казан. ун-ты, 2011. 214 б.

Җыентык эчендәге язма

Беломоина Н.А. Милли журналистиканың торышы // Татар журналистикасы XXI гасырда. Үсеш юллары: фәнни-гамәли конференция материаллары, Казан: Казан. ун-ты, 2011. С. 6-10.

Күп томлы басмалар

Гегель Г.В. Соч. М., 1939. Т.4. С. 32.

Журналда басылган мәкалә

Тагиров И. Мирсаид Султан-Галиев: “Признания” // Гасырлар авазы. Эхо веков. 2011. №3/4. Б. 57-68.

Диссертацияләр

Сабирова Л.Р. Речевые особенности жанра интервью на татарском языке (на материале современных СМИ): дис. … канд. филол. наук. Казань, 2010. 221 с.

Диссертациянең авторефераты

Сабирова Л.Р. Речевые особенности жанра интервью на татарском языке (на материале современных СМИ): автореф. дис. ... канд. фил. наук. Казан, 2009. 23 с.

Рәсми материал

Конституция Российской Федерации: офиц. текст. М.: Маркетинг, 2001. 39 с.

Конференция материаллары

Татар журналистикасы XXI гасырда. Үсеш юллары: фәнни-гамәли конференция материаллары, 11 февр., 2011 ел. Казан: Казан. ун-ты, 2011. 214 б.

Газетадан мәкалә

Муллаянова Р. Сугыш санарга өйрәтте // Ватаным Татарстан. 2012. 9 март.

Кышкы интервью // Ватаным Татарстан. 2011. 11 февр.

Интернеттан алынган язмалар

Официальные периодические издания: электронный путеводитель / Рос. нац. б-ка, Центр правовой информации [СПб], 2005-2007. URL: http://www.nlr.ru/lawcenter/izd/index.html (дата обращения: 18.01.2007).

Телевизион тапшыру

Халкым минем. “Яңа гасыр” телерадиокомпаниясе. 2012. 2 апр. 19 сәг. 15 мин.

Телевизион реклама

Болгар радиосы рекламасы. “Яңа гасыр” телерадиокомпаниясе. 2012. 29 март. 18 сәг. 18 мин.

Радиотапшыру

Тел күрке сүз. ТДТРК. 2002. 7-15 апр. 12 сәг. 15 мин.

Китаплар турында мәгълүмат биргәндә Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләренең атамалары кыскартып бирелә.

М., С-Пб.

Татарча хезмәтләрдә Казан шәһәре атамасы да кыскартыла.

К.

Массакүләм-мәгълүмат чараларының хронологиясен биргәндә, ай исемнәрен кыскартып бирү кирәк:

гыйнвар – гыйнв.,
февраль – февр.,
март (кыскартылмый),
апрель – апр.,
май (кыскартылмый),
июнь (кыскартылмый),
июль (кыскартылмый),
август – авг.,
сентябрь – сент.,
октябрь - окт.,
ноябрь (кыскартылмый),
декабрь – дек.

Чыганаклар

Чыганакларны күрсәткәндә шул ук принциплар саклана. Әйтик, газета язмасы фәнни әдәбият буларак файдаланылса да, чыганак буларак кулланылса да, библиографиядә болай күрсәтелә:

Бәйрәмова Ф. Кыпчак даласында татар каласы // Мәдәни җомга. 2006. 20 гыйнв.

Сылтама һәм астөшермәләр

Курс эшен язу барышында кулланылган цитаталарның чыганагы искәрмә итеп күрсәтелә. Ул өч төрле юл белән башкарыла: астөшермә рәвешендә, текст эчендә һәм текст азагындагы әдәбият исемлегенә сылтама ясау ысулы белән.

Астөшермә

Галиева Р.М. Татарские сатирические журналы начала XX века. Казань. Казан. гос. ун-т, 2010. С. 70-71.

Бер үк материал шул биттә берничә мәртәбә кабатланса, ул очракта исеме тулысынча бер мәртәбә генә языла, ә калган очракта түбәндәгечә куела:

Шунда ук. Б.10.

Текст эче искәрмәсе

Текст эчендә әдәбият исемлегенә, цитаталарга сылтама берничә төрле вариантта язылырга мөмкин. Фәнни эш барышында аның бер төрен генә куллану дөрес.

Ни кызганыч, бу сезонда театрларда югалтулар да шактый булды[5].

Шулай ук чыганак турындагы мәгълүмат китерелгән мисалдан соң бирелә (Шәһри Казан, 2012, 30 март.)

Чыганаклар күп тапкырлар кабатланганда, аны кыскартып бирергә була:

Мәсәлән, “Без “Шәһри Казан” газетасын чыганак буларак кулландык”. (алга таба – Ш.К.)

Бер үк китапка берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән очракта искәрмәләр түбәндәгечә күрсәтелә:

Низамов И.М. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 25.

Шунда ук. Б. 41.

Текст азагындагы әдәбият исемлегенә сылтама ясаганда, хезмәтнең әдәбият исемлегендәге саны шакмаклы җәяләр эчендә күрсәтелә:

Бу проблема Р.У.Әмирханов [1] тарафыннан җентекле өйрәнелгән.

Фәнни хезмәтнең аерым битләренә искәрмә ясаган очракта түбәндәгечә язалар:

И.М.Низамов аларны газетизм дип билгели [4, б. 66].

Беренче сан әдәбият исемлегендә әлеге китапның ничәнче булып язылганын аңлатса, икенчесе бит санын күрсәтә.

Бер авторның берничә хезмәтенә яисә берничә галим хезмәтенә искәрмә ясалганда, җәяләр эченә нокталы өтер аша әлеге хезмәтләрнең әдәбият исемлегендәге тәртип санын куялар:

Татар журналистикасы фәнендә әлеге проблемага карата шактый хезмәтләр язылган [4; 11; 13].

Архив документлары

Архив документларына библиографик сылтамалар аның кайда урнашканлыгын ачыклый. Документлар архивларда, музейларда һәм китапханәләрдә саклана.

[5] Шәһри Казан. 2012. 30 март.

Документның исеме, эзләү мәгълүматлары, объектның урынына сылтама, саклау берәмлеге күрсәтелә.

Теге яки бу документны эзләгәндә, архив исеме, фонд, опись номеры, эшнең бите языла. Бөтен эзләү элементлары нокталар аша бирелә. Мәсәлән, ОР РНБ. Ф.316. Д.161.Л.1.

РО ИРЛИ. Ф. 568. Оп.1. №196. Л. 18-19 об.

Архив исемнәре кыскартылып та күрсәтелергә мөмкин. Мәсәлән, текстта берничә мәртәбә кабатлаулар булганда:

Арх. РГБ.

Бит асты һәм текст азагында документ хакында мәгълүмат түбәндәгечә бирелә (документ хакындагы мәгълүматлар эзләү мәгълүматларыннан ике кыек сызык белән аерыла):

7 Розанов И.Н. Как создавалась библиотека Исторического музея: докл. на заседании Ученого совета Гос. публ. ист. б-ки РСФСР 30 июня 1939 г. // ГАРФ. Ф. А-513. Оп. 1. Д. 12. Л.14.

36 Материалы об организации Техникума печати при НИИ книговедения // ЦГАЛИ СПБ. Ф. 9. ОП.1. Ед. хр. 109.

4. Северо-Западное бюро ЦК ВКП (б). Общий отдел. Протоколы // ЦГАИПД. Ф.9. Оп. 1. Ед. хр. 109.

28. Логинов М.Н. Письма (9) С.Д. Полтарацкому. 1857-1860 гг. // ОР РНБ. Ф. 603 (С.Д.Полтарацкий). Д. 145. 15 л.

Фәнни эштә искәрмәләр куллану һәм библиография аппаратын белү – барысы да фәнни эшне башкарганда кулланылган, укылган, өйрәнелгән әдәбият исемлеген төзү өчен кирәк. Чөнки кечкенә генә, мәсәлән, реферат, доклад кебек фәнни эшләрне башкарганда да, студент әдәбият исемлеген күрсәтергә тиеш. Бу әлеге темага карата башкаларның фикерен белү, алар белән килешү һәм бәхәскә керү өчен кирәк. Аннан теге яки бу теманы өйрәнүчеләр булгандыр, шуның өчен дә темаңны тулырак күзаллау өчен дә әдәбиятка күзәтү ясау мөһим.

ЯКЛАУ ТӘРТИБЕ

Гадәттә студентлар фәнни язма эшне махсус график буенча курсташлары һәм комиссия әгъзалары алдында яклый. Студент 7-10 минут дәвамында үз эшенең темасы, максат-бурычлары, төп нигезләмәләре, нәтиҗәләре белән таныштыра. Аннан студентка сораулар бирелә. Җаваплардан соң рецензент сөйли (3-4 минут). Ул эшкә үз бәясен бирә,

теманың дөрес сайлау-сайланмавы турында әйтә, уңышлы-уңышсыз якларын күрсәтә. Фәнни эш авторы аның да сорауларына, тәнкыйди фикерләренә, теләк-тәкъдимнәренә мөнәсәбәтен белдерә, җавап бирә.

Курс эшенә бәяне укытучылардан торган комиссия, диплом эшенә – Дәүләт аттестация комиссиясе чыгара.

Әлбәттә, эшне бәяләгәндә, комиссия, тәкъдим ителгән фәнни хезмәтнең башкару сыйфатын, дәүләт стандартларына туры китереп әзерләнгәнлеге белән беррәттән, студентның кыска гына вакыт эчендә үз хезмәтенең асылын аңлата белүен, фәнни дискуссия барышында югалып калмавын, аудитория алдында үз-үзен тотышын да исәпкә ала.

БӘЯЛӘМӘ ЯЗУ ТӘРТИБЕ

Фәнни эшне яклар өчен аның башкалар тарафыннан укылган булуы, бәя бирүләре сорала. Курс эшләренә бәяне төркемдәшең һәм җитәкчең язса, диплом эшенә бәяне кафедра тарафыннан билгеләнгән рецензент һәм фәнни җитәкче яза.

Бәяләмә-рецензия язуның үз тәртибе бар. Фәнни җитәкче, рецензентларның бәяләмәсе ирекле формада языла һәм түбәндәге сорауларны үз эченә ала **(кара: 3, 4, 5 кушымта):**

1. Фәнни эшнең эчтәлеге куелган максат һәм бурычларга, теманың актуальлегенә туры киләме?
2. Куелган сораулар нигезле дәлилләнгәнме?
3. Мөстәкыйль эшләү сыйфаты ни дәрәҗәдә?
4. Студент башкаларның хезмәтен өйрәнә һәм гомумиләштерүләр ясый алганмы?
5. Дөрес нәтиҗәләр чыгарылганмы?
6. Материал ни дәрәҗәдә өйрәнелгән?
7. Рецензентны тагын нинди сораулар борчый?
8. Фәнни эшнең кимчелекләре нинди?
9. Фәнни эшнең киләчәктә кулланылышы бармы?
10. Студент нинди билгегә лаек?

Дата

Имза

БАЛЛ-РЕЙТИНГ СИСТЕМАСЫ РЕГЛАМЕНТЫ

Фәнни эшне яклау графигы һәм комиссия әгъзалары кафедра утырышында билгеләнә.

Апрель азагында чыгарылыш квалификация эшенең яклау алды коммисиясендә җавап тоту каралган (зачет).

Яклау вакыты: агымдагы елның май-июнь айлары.

Семестр дәвамында эш тәртибе

№ п/п	эш төре	вакыты	балл (max)
1	Билгеләнгән срокта тема сайлау; җитәкче белән аралашу	15 октябрь	**5**
2	Әдәбият һәм чыганаклар белән эшләү; диплом эшен планлаштыру	декабрь	**30**
3	Фәнни җитәкче янына консультациягә йөрү; диплом эшенең барышы белән таныштыру	уку елы дәвамында	**20**
4	Чыгарылыш квалификация эшенең вакытында үтәлеше һәм тапшыруы	апрель-май	**5**
5	Диплом эше тематикасы буенча фәнни гамәли конференцияләрдә катнашып, чыгыш ясау (өстәмә балл)	гыйнвар-апрель	**5**

Аттестацияләү барышы

№ п/п	бәяләү критерийләре	балл (max)
1	Фәнни эшнең эчтәлеге куелган максат һәм бурычларга, теманың актуальлегенә туры килүе	**10**

2	Студентның мөстәкыйль эшләве, фәнни тикшерүнең оригинальлеге	**5**
3	Чыганаклар һәм фәнни әдәбият белән актив эшләве	**5**
4	Чыгарылыш квалификация эшенең төзелеше камиллеге, ГОСТ таләпләренә туры килүе	**5**
5	Яклауда чыгыш ясау, сорауларга җавап бирү	**15**

Чыгарылыш квалификация эшен бәяләү

аттестация төре	**балл (max)**
Семестр дәвамында эш тәртибе	**55**
Өстәмә балл	**5**
Яклау	**40**
Барлыгы:	**100**

Балларның билгедә чагылышы

балл	**билге**
33-54	“Канәгатьләнерлек түгел”
55-70	“Канәгатьләнерлек”
71-85	“Яхшы”
85-100	“Бик яхшы”

1, 2, 3 курс студентлары (көндезге бүлек) курс эшен апрель аеның икенче яртысында, 2 курслар декабрь аенда яклый.

ТЕМАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

021400 – Татар журналистикасы буенча курс һәм чыгарылыш квалификация эше (диплом) темалары

Фәнни җитәкче филология фәннәре докторы,
профессор Гарифуллин В.З.

Вакытлы матбугат, жанрлар

1. Репортерның эш алымнары.
2. Сайлаган тема нинди жанр таләп итә?
3. Интервью – жанр да, метод да.
4. Репортер күзлегеннән шәһәр тормышы.
5. Татар матбугатында криминаль тема.
6. Газета битендә – замандаш портреты.
7. Газета дизайны: заман таләпләре.
8. Матбугат хезмәте: булышамы әллә аяк чаламы?
9. Журналистика һәм хакимият.
10. Балалар басмаларының типологиясе.
11. Корпоратив матбугат, функцияләре, үзенчәлекләре.
12. Журналист иҗатында гадәти булмаган формалар.
13. Матбугатта сәяси реклама.
14. Матбугат тибы буларак муниципаль газета.
15. Җирле матбугатта милли тематика.
16. Журналистның иҗади лабораториясе.
17. Журналист иҗатында бәя төрләре.
18. Бәя бирүдә тел чаралары.
19. Дини басманың тел үзенчәлекләре.
20. XX йөз башы журналистикасында сатирик жанрлар.
21. Хәзерге матбугатта бәхәс.
22. Аудиторияне ничек өйрәнергә?
23. Матбугатта конфликтлар чагылышы.
24. Хәзерге журналистикада эксперимент.
25. Журналистның социаль җаваплылыгы.
26. Журналистикада яшьләр образы.
27. Журналист һәм сенсация.
28. Жанр төре буларак анонс.
29. Телевизион журналистның иҗади портреты, тәнкыйть.
30. Имидж тудыру чарасы буларак мәгълүмат органы.

31. Интернет аша хәбәр тапшыруның үзенчәлекләре.
32. FM радиода мәгълүмат җиткерү.
33. Татарча хосусый мәгълүмат чараларының үзенчәлекләре.
34. Татар журналларының кушымталары: алар нәрсә белән ота.
35. Журналистика һәм социология дуслыгы.
36. Журналистикада шәхесне өйрәнү ысуллары.
37. Газетада хәбәренең төрләре.
38. Газетада интервью-портретның үзенчәлекләре.
39. Журналда интервью-портретның үзенчәлекләре.
40. Репортажда «катнашу эффекты»н тудыру чаралары.
41. Парламент хисабы. Аның осталары.
42. Балалар газетасына ничек язмаска?
43. Республикабыз матбугатында диаспора тормышы.
44. Газетада форма һәм эчтәлек бердәмлеге.
45. Яңадан туу: Татарстаннан читтә чыгучы татар матбугатына анализ.
46. Татар газетасында башламнар.
47. Татар матбугатында баш исемнәренең үсеш-үзгәреше.

Журналист эшчәнлеге нигезләре

1. Журналистның шәхси иҗади йөзе. Ул ничек формалаша?
2. Матбугатта милли мәгариф проблемалары.
3. Икетеллелекне тормышка ашыруда матбугатның роле.
4. Радионың яшьләр аудиториясенә тәэсир итү чаралары.
5. Журналист иҗатының үзенчәлекләре.
6. Журналист иҗатында ассоциация.
7. Иҗатка сыйфатлама.
8. Журналист иҗатында интуициянең роле.
9. Журналист иҗатында аралашу.
10. Журналист әсәрен иҗат итүнең үзенчәлекләре.
11. Журналист әсәрен бәяләү күрсәткечләре.
12. Текст тудыру гамәлләре.
13. Күзәтү методы.
14. Татар журналистлары иҗатында эксперимент.
15. Иҗат ысулына гомуми сыйфатлама.
16. Журналистикада текст типлары.
17. Аралашуда туган киртәләрне җимерү алымнары.
18. Журналистикада фактологик текстлар.
19. Иҗат методы буларак әңгәмә.

20. Журналист иҗатында фактларның роле.
21. Журналист әсәрен тудырганда фәнни методлар.
22. Журналистикада дәлилләүле текстлар.
23. Иҗат этәргече чыганаклары.
24. Журналистикада тасвири текстлар.
25. Журналист әсәренең эчтәлеге элементлары.
26. Журналистикада диалогик текстлар.

Журналист осталыгы

1. Үткен каләм остасы (яраткан журналистым иҗатына штрихлар)
2. А.Хәлим (Т.Миңнуллин, Р.Вәлиев, Р.Миңнуллин, Ф.Баттал һ.б.) публицистикасында милли проблематика.
3. Татарда сәяси журналистика осталары.
4. Икътисад журналистикасы: үсеш юллары.
5. Сайлаулар һәм матбугат.
6. Журналистикада икътисад мәсьәләләре.
7. Район газетасы ничек сулый?
8. Мөһаҗирлектәге татар матбугатының сикәлтәле юллары.
9. Беренче татар газеталарының өйрәнелү тарихы.
10. Татар журналистикасы тарихын өйрәнүчеләр.

Фәнни җитәкче филология фәннәре докторы,
профессор Низамов И.М.

Татарча әдәби редакцияләү

1. Ш.Мәрҗани (К.Насыйри, И.Гаспралы, Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими, С.Максудый, Г.Исхакый, М.Бигиев, Х.Ямашев, Г.Камал, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Әхмәдиев, М.Вахитов, Г.Баембитев, С.Атнагулов, М.Борһан, М.Җәлил, Ш.Хамматов һ.б.) – мөхәррир һәм редактор.
2. Газета материалларында мантыйкый хаталар, аларны төзәтү алымнары (бер журналист яисә газета мисалында).
3. Хатларны редакцияләгәндә фактик хаталарны төзәтү. Төрләрен системалау (бер журналист яисә газет мисалында).
4. Атналык газетада композиция, рубрикацияләү.
5. Газета материалларын төзәткәндә автор белән эш. Автор хокукы (бер редакция тәҗрибәсе).
6. Китап редакторының автор белән эшләү үзенчәлеге.
7. Эчтәлек һәм форма бердәйлеге. Төзәткәндә жанр таләпләрен саклау.

8. Сүз – төзәтүдә дә төп корал (район газетында тел хаталары, аларны бетерү юллары).

9. Төзәтү – ул сөйләм оештыруның бер төре. Укучы – редактор – автор. Сөйләм мотивларына карап тел һ.б. чараларны урынлы куллану.

10. Тәрҗемә текстын редакцияләү үзенчәлеге (“Татарстан” журналы тәрҗемәчеләренең иҗади йөзе).

11. Язма һәм әйтмә текст каршылыкларын бетерү юллары (радио тексты мисалында).

12. Катнаш текстны төзәтү үзенчәлеге (телевидение сөйләме мисалында).

13. Интернет сөйләмендә редактор эшчәнлеге.

14. Журналда рубрикацияләү. Бизәлеш белән текст нисбәте (“Сөембикә”, “Идел”, “Ялкын” “Чаян” журналлары мисалында).

15. Татар классиклары әсәрләрен бастыру тәҗрибәсе (редактор Рәис Даутов архивыннан).

16. Татар календарен редакцияләү үзенчәлеге (В.Шәрипованың иҗат тәҗрибәсе).

17. Редакторның татар телен саклау, үстерүдә тоткан урыны.

18. “... редакторның шәхси иҗади йөзе” (Бер күренекле татар редакторының иҗат тәҗрибәсе).

19. Бүгенге татар орфографиясе кагыйдәләренә редактор күзәтүе.

20. Рәис Даутовның редактор эшчәнлеге тәҗрибәсе.

21. Эссе жанры үсештә (эссечы Рафаэль Сибат тәҗрибәсе).

22. Мансур Мортазинның редакторлык эшчәнлеге.

23. Илсөяр Хәйруллина – яңалыкка омтылучы журналист.

24. Яңа технологияләр һәм татарча редакцияләү тәҗрибәсе (электрон, аудио, видео текстларны төзәтү эшчәнлеге).

25. Корпоратив мәгълүмат чаралары һәм татар теле.

Татар сөйләме нигезләре

1. Сезнең төбәктә мөрәҗәгать итү, исәнләшү, танышу, саубуллашу рәвешләре, тел чаралары.

2. Авыл сөйләме белән шәһәр сөйләме арасында аермалы һәм уртак яклар.

3. Гаиләдә төрле шивә (диалектларда), төрле телләр кулланып аралашу үзенчәлеге.

4. Оста язучының (Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Һ.Такташ, Ә.Еники, Г.Бәширев, Ф.Хөсни, Х.Сарьян, М.Мәһдиев, Т.Миңнуллин) үзенчәлекле сөйләме нидән гыйбарәт?

5. “Газет теле” төшенчәсенең аерым бер газет сөйләмендә чагылышы (диахроник һәм синхроник яссылыкта).

6. Татар фикерләвендә фәнни-популяр сөйләм (“Мәгариф” журналы мисалында).

7. Татар фикерләвендә рәсми-популяр сөйләм (Министр Марат Әхмәтев сөйләме мисалында).

8. “Сөембикә” журналында шәфкать, мәрхәмәт, кешелеклек, ана мәхәббәте һ.б. хисе укучыга ничек җиткерелә?

9. “Чаян” журналында көлү, көлдерү, сатира алым-чаралары.

10. Сөйләм төре буларак жанр (журналистиканың һәр төр (хәбәри, аналитик, әдәби-публицистик) җанрын анализларга була).

11. Гаиләдә (балалар бакчасында, мәктәптә һ.б.) үзләштерелә торган сөйләм төрләре.

12. Телевидение тапшыруларында әйтмә, язма, күрсәтмә чараларның синтезын барлыкка китерү, куллану үзенчәлеге.

13. Радиотапшыруларда язма һәм әйтмә сөйләм бердәйлеге.

14. Язма драма әсәрен сәхнәдә куюның сөйләм төре буларак мөмкинлекләре.

15. Татарча интернет текстында сөйләм мотивларына карап тел һ.б. чаралар куллану үзенчәлеге.

16. Матбугатта татар теле – дәүләт теле темасы (2000–2012 еллар).

17. Габдулла Тукайның публицистик поэтикасы (кечкенә жанрларда тасвир чаралары).

18. Туфан Миңнуллинның әдәби-публицистик жанрларда тасвир чаралары (“Кызыл дәфтәр”дән кечкенә жанрлар мисалында).

19. Тәрбия-әхлак темасына очеркларда тәэсир чаралары (“Сөембикә”, “Идел” журналы мисалында).

20. Хәсән Сарьянның радио сөйләменә куйган таләпләре бүген ничек үтәлә? (“Яңа гасыр”, “Курай”, “Азатлык”, “Татар” радиоларына лингво-стилистик анализ).

21. Мәгълүмат чараларында яңа технологияләр һәм терминология.

22. Татарча термин ясау һәм куллану принциплары ничек үтәлә (бүгенге иҗтимагый-сәяси терминологиягә анализ).

23. Татар телен үстерүгә интернетның уңай һәм тискәре тәэсире (татарча сайтларга лингво-стилистик анализ).

24. Тәэсир чарасы буларак сүз, тавыш, хәрәкәт синтезы (телевидение сөйләмен камилләштерү тәҗрибәсе).

25. Татар теленең лексик составын баетуда мәгълүмат чаралары эшчәнлеге (2000–2012 еллар).

26. Татарстаннан тыш газетлар һәм татар теле (“Кызыл таң” газеты мисалында).

Татар риторикасы

1. Ышандыру (инандыру) максатында матбугатта кулланыла торган тел чаралары.

2. Ышандыру (инандыру) максатында радиода кулланыла торган тавыш-интонация чаралары.

3. Ышандыру (инандыру) максатында телевидениедә (яисә сәхнәдә) кулланыла торган паралингвистик (хәрәкәт) чаралары.

4. “Идегәй” дастанында борынгы нәфис сүзнең һәм башка риторик чараларның ышандыру үзенчәлеге.

5. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасында сүз сәнгатенең тәэсири чаралары.

6. Татар чичәннәренең милли риторика сәнгатен үстерүдәге урыны (Мифтахетдин Акмулла мисалында).

7. “Корьән”нең сүз сәнгатенә мөнәсәбәте. Аның татарча тәрҗемә текстларында риторик фигуралар, дәлилләү һәм тасвирлау чаралары.

8. Вәгазь сөйләү осталыгына ничек ирешелә (бер имам-хатыйп, мөгаллим мисалында).

9. Татар хөтбәчелеге турында Габдулла Бубый (Җиһангир Абызгилдин) фикерләре һәм хезмәтләре.

10. Ш.Мәрҗани (К.Насыйри, Р.Фәхретдин, Г.Исхакый, И.Гаспралы, Ф.Кәрими) әсәрләрендә татар риторика сәнгатенә һәм фәненә керткән өлеш.

11. Шигърият һәм риторика (Г.Тукай, С.Рәмиев, М.Гафури, Ш.Бабич).

12. Театр һәм драматургия – татар риторикасы нигезендә (Г.Кариев, С.Гыйззәтуллина-Волжская, К.Камал, М.Мутин һ.б.).

13. Инкыйлабый ораторлык осталыгы (С.Максудый, М.Вахитов, М.Солтангалиев һ.б.).

14. Бүгенге иҗтимагый-сәяси ораторлык осталыгы (бер министр, район башлыгы сөйләме мисалында)

15. Мәхкәмә сөйләме (адвокат, гаепләүче, гаепләнүче, судья һ.б.) төренең ышандыру чаралары (Әтнә, Актаныш, Мөслим халык мәхкәмәләре мисалында).

16. Вәгазь жанрында риторик тәэсир чаралары (“Кол Шәриф” мәчете имам-хатыйбы Рамил Юнысов вәгазьләре).

Фәнни җитәкче филология фәннәре кандидаты,
доцент Зәйни Р.Л.

Журналистиканың хокукый нигезләре

1. Матбугат иреге мәсьәләләренең матбугатта яктыртылышы.
2. Массакүләм мәгълүмат чараларының җәмгыятьтә тоткан хокукый урыны.
3. ММЧ эшчәнлеген билгеләүче редакция уставларының төп үзенчәлекләре.
4. Шәхес намусын саклау өлкәсендә журналист эшчәнлеге.
5. Журналистикада милләтара килешүчәнлек һәм ызгышлар мәсьәләсе.
6. Матбугатта авторлык хокукы һәм плагиат проблемасы.
7. Россиядә “ММЧ турындагы” законның бәхәсле урыннары.

Журналистика эшчәнлеге нигезләре. Аналитик жанрлар

1. Татар матбугатында эксперимент жанрын куллану үзенчәлекләре.
2. Татар матбугатында социологик тикшеренү алымын куллану үзенчәлекләре.
3. Журналист тикшерүе жанрының матбугатта кулланылышы.
4. “...” журналында рецензия жанрын куллану үзенчәлекләре.
5. Татар матбугатында мәкалә жанры эволюциясе.
6. Татар матбугатында бәхәс алып бару үзенчәлекләре.

